| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СТАРОСЛЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЭСЛӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2022 с. Иске Эсләк авылы № 5

«Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Иске Эсләк авыл жирлегендә гражданнарның мөрәжәгатьләрен анализлауны уздыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 06 февралендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәжәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясындагы 2, 3 өлешләре нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокурорының «Гражданнар мөрәжәгатьләрен карау өлкәсендә законнарны бозуларны бетерү турында» 2021 елның 11 ноябрендәге 02-08-02-2021/287 номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлегендә гражданнарның кергән мөрәжәгатьләрен анализлау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 06 февралендәге 4 номерлы карарына кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Иске Эсләк авыл жирлеге мәгълүмат стендында урнаштыру тәртибендә халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе Д.М.Ахметов

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районының Иске Эсләк
авыл жирлеге Башкарма комитеты
карары белән расланган

**1«Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Иске Эсләк авыл жирлегендә гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районыИске Эсләк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 06 февралендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр**

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Иске Эсләк авыл жирлегенең Башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлегендә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибендә:

1) 4 пунктында:

«Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерә» сүзләреннән соң «һәм хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи» сүзләрен өстәргә.»;

2) 6 пунктында:

«елга ике тапкыр» сүзләреннән соң «Гражданнар мөрәҗәгатьләре» бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 санына кадәр» сүзләрен өстәргә.